# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылы торак пунктында граждannар
җыены нәтиҗәләре турында

**15 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2025 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яхшы Каран торак пункты территориясендә теркәлгән инвалидлардан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр) һәм көндезге уку формасы буенча укучы, хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәтләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Яхшы-Каран т.п. урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
2) Яхшы-Каран авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
3) Мифтахов урамы буенча вак таш өслек ремонтлауны, (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне);
4) Яхши-Каран авылында һәйкәлләрне ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү ( ремонт, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 69 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 47 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 47 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яхшы Каран торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, инвалидлардан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр) һәм көндезге уку формасы буенча укучы, хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәтләрдән тыш, яшәү урыны

буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Яхшы-Каран т. п. Идрисов хэм Мифтахов урам юлларына вак таш җәю;

1) Яхшы-Каран т.п. урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) Яхшы-Каран авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Мифтахов урамы буенча вак таш өслек ремонтлауны, (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне);

4) Яхши-Каран авылында һәйкәлләрне ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү ( ремонт, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Александровка авыл җирлегенең Татар мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин